СОВЕТ НИЖНЕОШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.37А, с.Нижняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422164

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН УШМЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Совет ур., 37А нче йорт, Түбән Ушмы авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422164

тел.(факс): (85563) 2-34-46; e-mail: Noshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

№ 2-10 «10» июнь 2016 ел

« Түбән Ушмы авыл җирлеге территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын җыюны, алып китүне, утильләштерүне һәм эшкәртүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 10 июлендәге 1-35 номерлы Мамадыш муниципаль районының Түбән Ушмы авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законнар, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2016 елның 11 апрелендәге № 10-614в-2016/3 протесты, муниципаль берәмлек Уставы нигезендә Түбән Ушмы авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Түбән Ушмы авыл җирлеге территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын җыюны, алып китүне, утильләштерүне һәм эшкәртүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 10 июлендәге 1-35 номерлы Мамадыш муниципаль районының Түбән Ушмы авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районының Түбән Ушмы авыл җирлеге башлыгы Р.М. Ганиевка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Ушмы авыл җирлеге башл
Совет рәисе Р.М. Ганиев